**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 25 май № 372

г. Казань

Вакытлыча социаль файдалануга алынган йортлар һәм аларны төзү өчен бирелгән яки билгеләнгән җир кишәрлекләрен исәпкә алу турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 91$^{18}$ статьясындагы 2 өлеш, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 ел, 16 март, 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьсы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Вакытлыча социаль файдалануга алынган йортлар һәм аларны төзү өчен бирелгән яки билгеләнгән җир кишәрлекләрен исәпкә алу тәртибен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\372.doc

Вакытлыча социаль файдалануга алынган
йортлар һәм аларны төзү өчен бирелгән яки
билгеләнгән җир кишәрлекләрен исәпкә алу
Тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

**Вакытлыча социаль файдалануга алынган йортлар һәм аларны төзү өчен бирелгән яки билгеләнгән җир кишәрлекләренең муниципаль реестры**

| реестр саны | реестар санын бирү датасы | жир кишәрлеге турында белешмәләр составы | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | объект исеме | адресы (урнашу урыны) | кадастр саны | жир кишәрлеген кадастр исәбенә кую датасы | мәйдан, кв.метр | җирләр категориясе | рөхсәт ителгән файдалану | хокукка ия булучы турында белешмәләр (тулы исеме, тдтс), анын әйбергә хокукын күрсәтеп | җир кишәрлегенә карата куелган чикләүләр турында, аларның килеп чыгу һәм туктатылу нигезләрен һәм датасын күрсәтеп | төзелеш өчен җир кишәрлеге бирү турында карар реквизитлары | объектның исеме | адресы (урнашу урыны) | кадастр саны (кадастр саны бирелгән очракта тутырыла) | фатирлар саны | гомуми мәйдан, кв.метр | торак мәйдан, кв.метр | эксплуатацияләүгә кертү елы | хокукка ия булучы турында белешмәләр (тулы исеме, тдтс), анын әйбергә хокукын күрсәтеп | социаль файдалануга алынган йортны файдалану максаты үзгәрү турында белешмәләр | социаль файдалануга алынган йортны файдалану максаты үзгәрү турында карар реквизитлары |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Вакытлыча социаль файдалануга алынган йортлар һәм аларны төзү өчен бирелгән яки билгеләнгән җир кишәрлекләрен исәпкә алу Тәртибенә 3 нче кушымта

Форма

______________________________
(җирле үзидарәнен
______________________________
вәкаләтле органы
____________________житәкчесенә
исеме)

Вакытлыча социаль файдалануга алынган йортларның муниципаль реестрында булган мәгълүматларны бирү турында
сорату

Вакытлыча социаль файдалануга алынган йортларның муниципаль реестрында булган ________________________________________________
(сорату гамәлгә ашырыла торган исәпкә алу объекты исеме һәм
______________________________________________________мәгълүматларны
урнашу урыны)
яки күрсәтелгән Реестрда соратылган мәгълүматларның булмавы турында мәгълүмат бирүегезне сорыйм.

Гариза бирүче (физик зат) турында белешмәләр:

| | |
|---|---|
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Шәхесен таныклаучы документ төре | |
| Шәхесен таныклаучы документның сериясе һәм саны | |
| Шәхесен таныклаучы документ кем тарафыннан бирелгән | |
| Шәхесен таныклаучы документны бирү вакыты | |
| Телефоны | |
| Почта адресы | |
| Электрон почта адресы | |
| Имза | |
| Сорату датасы | |

Гариза бирүче (юридик зат, дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы) турында белешмәләр:

| | |
|---|---|
| Тулы исеме | |
| Телефоны | |
| Почта адресы | |
| Электрон почта адресы | |
| Җитәкче вазыйфасы | |
| Җитәкче имзасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Сорату датасы | |

М.У.

Вакытлыча социаль файдалануга алынган йортлар һәм аларны төзү өчен бирелгән яки билгеләнгән җир кишәрлекләрен исәпкә алу Тәртибенә 4 нче кушымта

Форма

ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ ВӘКАЛӘТЛЕ ОРГАНЫ

Вакытлыча социаль файдалануга алынган йортларның муниципаль реестрыннан ӨЗЕМТӘ

20__ елның «_____» ________ торышына вакытлыча социаль файдалануга алынган йортларның муниципаль реестрында түбәндәге белешмәләр бар:

| Т\с | Параметр (реквизит) исеме | Эчтәлеге |
|---|---|---|
| 1. | Җир кишәрлеге турында белешмәләр составы: | |
| | Объект исеме | |
| | адресы (урнашу урыны) | |
| | кадастр саны | |
| | җир кишәрлеген кадастр исәбенә кую датасы | |
| | мәйданы, кв.метр | |
| | җирләрнең категорияләре | |
| | рөхсәт ителгән файдалану | |
| | аның әйбергә хокукын күрсәтеп, хокукка ия булучы турында белешмәләр | |
| | җир кишәрлегенә карата мөнәсәбәттә урнаштырылган чикләүләр (мәшәкатьләр), аларның барлыкка килүе һәм туктатылуы нигезләрен һәм датасын күрсәтеп | |
| | төзелеш өчен җир кишәрлеге бирү турында карар реквизитлары | |
| 2. | Вакытлыча файдалануга алынган йорт турында белешмәләр составы: | |
| | объект исеме | |
| | адресы (урнашу урыны) | |

| Т\с | Параметр (реквизит) исеме | Эчтәлеге |
|---|---|---|
| | кадастр саны (кадастр саны бирелгән очракта тутырыла) | |
| | фатирлар саны | |
| | гомуми мәйдан, кв.метр | |
| | торак мәйдан, кв. метр | |
| | эксплуатацияләүгә кертү елы | |
| | аның әйбергә хокукын күрсәтеп, хокукка ия булучы турында белешмәләр | |

Белешмәләр _______________ елдагы №_________________

______________________________________________________________

(Ф.И.Ат.и., гариза бирүче исеме)

соратуы буенча бирелде.

М.У.

_______________________ ___________________ ______________________________

(вазыйфасы) (имза) (Ф.И.Ат.и.)

F:\KARAR\2015\372-3.docx

Вакытлыча социаль файдалануга алынган йортлар һәм аларны төзү өчен бирелгән яки билгеләнгән җир кишәрлекләрен исәпкә алу Тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

## Вакытлыча социаль файдалануга алынган йортлар һәм аларны төзү өчен бирелгән яки билгеләнгән җир кишәрлекләрен исәпкә алу картасы

| Т\с | Параметр (реквизит) исеме | Эчтәлеге |
|---|---|---|
| 1. | Җир кишәрлеге турында белешмәләр составы: | |
| | объект исеме | |
| | адресы (урнашу урыны) | |
| | кадастр саны | |
| | җир кишәрлеген кадастр исәбенә кую датасы | |
| | мәйдан, кв.метр | |
| | җирләр категориясе | |
| | рөхсәт ителгән файдалану | |
| | аның әйбергә хокукын күрсәтеп, хокукка ия булучы турында белешмәләр | |
| | җир кишәрлегенә карата мөнәсәбәттә урнаштырылган чикләүләр (мәшәкатьләр), аларның барлыкка килүе һәм туктатылуы нигезләрен һәм датасын күрсәтеп | |
| | төзелеш өчен җир кишәрлеге бирү турында карар реквизитлары | |
| 2. | Вакытлыча файдалануга алынган йорт турында белешмәләр составы: | |
| | объект исеме | |
| | адресы (урнашу урыны) | |
| | кадастр саны (кадастр саны бирелгән очракта тутырыла) | |
| | фатирлар саны | |
| | гомуми мәйдан, кв.метр | |
| | торак мәйдан, кв. метр | |
| | эксплуатацияләүгә кертү елы | |
| | аның әйбергә хокукын күрсәтеп, хокукка ия булучы турында белешмәләр (тулы исеме, ТДТС) | |

Җитәкче ______________________ ______________________________________

(имза) (Ф.И.Ат.и.)

М.У.

Искәрмә: исәпкә алу картасы кәгазьдә яисә электрон имза белән расланган электрон документ рәвешендә бирелә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 25 май, 372 нче
карары белән расланды

**Вакытлыча социаль файдалануга алынган йортлар һәм аларны төзү өчен бирелгән яки билгеләнгән җир кишәрлекләрен исәпкә алу тәртибе**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Торак кодексының $91^{18}$ статьясындагы 2 өлеш, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 ел, 16 март, 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьсы нигезендә эшләнде һәм социаль файдалануга алынган йортларның муниципаль реестрларында (алга таба – Реестр) социаль файдалануга алынган йортлар һәм аларны төзү өчен бирелгән яки билгеләнгән җир кишәрлекләрен исәпкә алу процедураларын билгели.

2. Реестрны алып бару территориясендә социаль файдалануга алынган йортлар һәм аларны төзү өчен бирелгән яки билгеләнгән җир кишәрлекләре урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль районы, шәһәр округы башкарма комитеты билгеләгән җирле үзидарә органы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Реестр Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районы, шәһәр округы территориясендә урнашкан социаль файдалануга алынган йортлар һәм аларны төзү өчен бирелгән яки билгеләнгән җир кишәрлекләре (алга таба – исәпкә алу объектлары) турында белешмәләрне үз эченә ала.

4. Реестрны алып бару әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтага ярашлы форма буенча электрон рәвештә гамәлгә ашырыла.

Территориясендә исәпкә алу объектлары урнашкан муниципаль районның, шәһәр округының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында исәпкә алу объектлары турында түбәндәге белешмәләр урнаштырылырга тиеш: адрес (урнашу урыны), кадастр саны (социаль файдалануга алынган йортларга карата – булганда) һәм хокукка ия булучы хакында белешмәләр (тулы исеме, ТДТС), аның әйбергә иялек хокукын күрсәтеп.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, социаль файдалануга алынган йортларны төзү өчен җир кишәрлекләре бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары территориясендә социаль файдалануга алынган йортларны төзү гамәлгә ашырылачак муниципаль районның, шәһәр округының вәкаләтле җирле үзидарә органына квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 10 көненнән дә соңга калмыйча, алар тарафыннан социаль файдалануга алынган йортларны төзү өчен җир кишәрлекләре формалаштырылу яки

алар тарафыннан социаль файдалануга алынган йортларны төзү өчен җир кишәрлеге бирелү хакында белешмәләр җибәрәләр.

6. Милкендә, биләп торуында, эш итүендә, идарә итүендә социаль файдалануга алынган йортлар булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар территориясендә социаль файдалануга алынган йортлар урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль районның, шәһәр округының вәкаләтле җирле үзидарә органына социаль файдалануга алынган йортны эксплуатацияләүгә керткән көннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча күрсәтелгән йортларны эксплуатацияләүгә кертү хакында, социаль файдалануга алынган йортны файдалану максаты үзгәрү, социаль файдалануга алынган йорт хакында белешмәләр составы үзгәрү турында, шулай ук социаль файдалануга алынган йорт урнашкан җир кишәрлеге хакында белешмәләр җибәрәләр.

## II. Реестрны алып бару тәртибе

7. Реестрны алып бару үз эченә түбәндәгеләрне ала:

Исәпкә алу объектын Реестрга кертү;

Исәпкә алу объекты турында үзгәргән белешмәләрне Реестрга кертү;

Исәпкә алу объектын Реестрдан чыгару.

8. Исәпкә алу объектлары турында белешмәләрне кертү милкендә, биләп торуында, эш итүендә, идарә итүендә социаль файдалануга алынган йортлар булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар территориясендә социаль файдалануга алынган йортлар урнашкан яки аларны төзү башкарылган муниципаль районның, шәһәр округының вәкаләтле җирле үзидарә органына әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтага ярашлы форма буенча тапшырган социаль файдалануга алынган йортларны һәм аларны төзү өчен бирелгән яки билгеләнгән җир кишәрлекләрен исәпкә алу карталары (алга таба – исәпкә алу карталары) нигезендә башкарыла.

9. Исәпкә алу карталарын алар кергән көндә вәкаләтле орган терки.

10. Исәпкә алу объектын Реестрга кертү өчен вәкаләтле орган исәпкә алу картасы кергән көннән соң 15 көн эчендә:

алардагы белешмәләрнең тулылыгын тикшерүне оештыра;

исәпкә алу карталарын тапшырган затлардан әлеге Тәртипнең 11 пунктында каралган очракларда һәм вакытта тәгаенләүче яисә аларда житмәгән мәгълүматны соратып ала;

белешмәләрне Реестрга кертә.

Әлеге пунктның өченче абзацында күздә тотылган сорату җибәрелгән очракта вәкаләтле орган тәгаенләүче яисә җитмәгән мәгълүмат кергән көннән соң 15 көн эчендә исәпкә алу объекты турында белешмәләрне Реестрга кертә.

11. Әлеге Тәртипнең 10 пунктындагы өченче абзац белән күздә тотылган сорату исәпкә алу карталары кергән көннән соң 5 көн эчендә вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге очракларда җибәрелә:

исәпкә алу объекты турында мәгълүмат исәпкә алу картасында тулы күләмдә түгел;

исәпкә алу картасы тексты аңлаешсыз, кыскартулар белән язылган;
исәпкә алу картасында чистартулар, өстәмә язулар, сызылган сүзләр һәм анда каралмаган бүтән төзәтүләр бар;
исәпкә алу картасы тексты карандаш белән язылган;
исәпкә алу картасында эчтәлеген бер генә мәгънәдә аңлатып булмый торган җитди бозулар бар.

Милкендә, биләп торуында, эш итүендә, идарә итүендә социаль файдалануга алынган йортлар булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар сорату кергән көннән соң 5 көн эчендә кергән соратуга җавап җибәрәләр.

12. Исәпкә алу объектын Реестрга керткән көннән соң 7 көн эчендә вәкаләтле орган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органына, җирле үзидарә органына, әлеге Тәртипнең 5 һәм 6 пунктлары нигезендә исәпкә алу карталарын тапшырган юридик затка тиешле белдерүне җибәрә.

13. Реестрга үзгәрешләр кертү һәм (яки) кертелгән белешмәләрне чыгару вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Тәртипнең 5 һәм 6 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар тапшырган, үз эченә үзгәртелгән (яңартылган) мәгълүматны алган яңа исәпкә алу карталары нигезендә гамәлгә ашырыла.

14. Социаль файдалануга алынган йортларны исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләрне тапшыруга карата торак законнары таләпләрен бозу законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

## III. Реестрда булган мәгълүматны тапшыру тәртибе

15. Реестрда булган исәпкә алу объектлары турында мәгълүматны вәкаләтле орган түбәндәгеләргә тапшыра:
федераль дәүләт хакимияте органнарына;
Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына;
җирле үзидарә органнарына;
милкендә, биләп торуында, эш итүендә, идарә итүендә исәпкә алу объектлары булган бүтән затларга.

16. Реестрда булган исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат язмача соратулар нигезендә әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтага ярашлы форма буенча сорату вәкаләтле органга кергән көннән соң 7 көн эчендә түләүсез бирелә.

17. Реестрда булган исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат түбәндәге форма буенча биреләләр:
әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтага ярашлы Реестрдан өземтәләр;
соратылган мәгълүматның булмавы турында белешмә.

18. Реестрда булган исәпкә алу объектлары турында соратуны карап тикшерү һәм алар хакында мәгълүмат бирү тәртибе Татарстан Республикасы муниципаль районнарының, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

---